**Татарстан Республикасы**
**Тукай муниципаль районы**
**«Биклән авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлек Советы**

# КАРАР

« 07»сентябрь 2018ел № 18/5

Татарстан Республикасы «Тукай муниципаль районы Биклән авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыеннарын әзерләү тәртибе турында » Нигезләмәне раслау хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясын, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясын һәм Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының «Биклән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 13.1 статьясын гамәлгә ашыру максатларында, Биклән авыл җирлеге Советы ,

**КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Биклән авыл җирлеге торак пунктларында, кушымта нигезендә, гражданнар җыеннарын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында» Нигезләмә расларга.

2. Әлеге карар Биклән авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында рәсми басылып чыккан мизгелдән үз көченә керә.

3. Аның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Биклән авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Муниципаль берәмлек башлыгы,
Совет рәисе М.Ш.Сахбеев